**КАРАР**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге Иске Чуриле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**25 ноябрь 2022 ел** **№ 7**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 24, 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чүриле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме?

- Җирле әһәмияткә ия булган машина юлына вак таш җәеп, юл полотносын ремонлау, Иске Чүриле авылы, Мәктәп урамы 12 йортан, Яңа урам 35 йортка кәдәр;
- Җирле әһәмияткә ия булган машина юлына вак таш җәеп, юл полотносын ремонлау, Иске Чүриле авылы, Яңа урам 13 йортан, Яшел урам 42 йортка кәдәр;
- Иске Чүриле авылында чишмәне төзекләндерү өчен материаллар сатып алу һәм ремонтлау;
- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм Яңа урамына урнаштыру;
- янгын сулыгына керү, юл – урам челтәрен тигезләү өчен машина юлларына вак таш сатып алу;
- Иске Чүриле авылы ерым янындагы санитар агач кисү һәм чыгару;
- Иске Чүриле авылы, Яңа урам 14 нче йорттан 20 нче йортка кадәр юлга вак таш, грунттан нигез салу;
- Иске Чүриле авылы, Яңа урамына, материаллар сатып алу һәм су челтәрләрен урнаштыру»

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау

хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 526 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 280 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 243 кеше тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 37 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегендә Иске Чүриле авылында халык җыенын булып узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чүриле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме?

- Җирле әһәмияткә ия булган машина юлына вак таш җәеп, юл полотносын ремонлау, Иске Чүриле авылы, Мәктәп урамы 12 йортан, Яңа урам 35 йортка кадәр;
- Җирле әһәмияткә ия булган машина юлына вак таш җәеп, юл полотносын ремонлау, Иске Чүриле авылы, Яңа урам 13 йортан, Яшел урам 42 йортка кадәр;
- Иске Чүриле авылында чишмәне төзекләндерү өчен материаллар сатып алу һәм ремонтлау;
- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм Яңа урамына урнаштыру;
- янгын сулыгына керү, юл – урам челтәрен тигезләү өчен машина юлларына вак таш сатып алу;
- Иске Чүриле авылы ерым янындагы санитар агач кисү һәм чыгару;
- Иске Чүриле авылы, Яңа урам 14 нче йорттан 20 нче йортка кадәр юлга вак таш, грунттан нигез салу;
- Иске Чүриле авылы, Яңа урамына, материаллар сатып алу һәм су челтәрләрен урнаштыру»

- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә , халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт адресы буенча, Арча муниципаль районның (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Һидиятуллин